ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№202 от «30» 05 2024 г.

Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 7 октябрендәге «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Мамадыш муниципаль районы хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1187 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 10 маендагы “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына үзгәрешләр кертү турында” 315 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 7 октябрендәге «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Мамадыш муниципаль районы хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1187 номерлы карарына (Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 7 декабрендәге 422 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең

0000012195

куркынычсызлыгын тәэмин итү шартлары турындагы нигезләмәнең II бүлегендәге «Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары» 1 нче таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

1 нче таблица

| № п/п | Хезмәткәрләрнең вазифалары | Хезмәт хакы күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | учреждение җитәкчесе | 25014,00 |
| 2 | Оператив дежур торучы | 19242,00 |

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ / веб адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче О.Н.Павлов